ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2022 № 744

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә «Мобиль укытучы» проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 8 апрелендәге 483 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга муниципаль районының ерак торак пунктларында урнашкан мәгариф учреждениеләрендә (оешмаларда) педагогик эшчәнлек алып баручы педагогик хезмәткәрләрне автомобильләр белән тәэмин итү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә «Мобиль укытучы» проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 8 апрелендәге 483 номерлы карары белән расланган, «Мобиль укытучы» проектын гамәлгә ашыру тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 бүлегендәге 2.1. пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирү сроклары - 15 июньнән 15 июльгә кадәр (ел саен)».

1.2. Тәртипнең 3 бүлегендәге 3.1.3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.3.1. Алабуга муниципаль районының ике һәм аннан да күбрәк гомуми белем бирү учреждениеләрендә бертөрле уку дисциплиналары (дисциплиналар цикллары) буенча вакантлы ставкалар булу һәм/яисә Алабуга муниципаль районының бер һәм аннан күбрәк гомуми белем бирү


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

учреждениеләрендә төрле уку дисциплиналары (дисциплиналар цикллары) буенча вакантлы ставкалар булу».

1.3. Тәртипнең 3 бүлегендәге 3.2. пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Беркетмә агымдагы елның 15 августына кадәр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырыла».

1.4. Тәртипнең 3 бүлегендәге 3.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Җиңүчеләрнең квотасын билгеләргә –1 кеше».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН